**Шәрипов, Әнвәр**. Яшәвенең мәгънәсе иҗат иде: язучы Газиз Кашапов турында истәлекләр / Ә. Шәрипов // Мәйдан. – 2022. – №11(252). – Б. 120-124.






*Язучы Газиз Кашапов турында истәлекләр*

Газиз Кашапов белән мин куп еллар буе аралашып, фикерләшеп, дус булып яшәдем. Аньң белән якыннан танышып китуем 1979-1980 елларга туры килә. 1978 елда мин Казаннан Алабуга techинситутына укытырга күчтем. 1980 елда институтнъщ башлангыч сыйныф укытучыларын әзерләү (педфак) һәм балалар бакчалары тәрбиячеләрен әзерләү (дошфак) факультетларын Чаллыга кучерделәр. Ул бүлекләрдә «Татар балалар әдәбияты» предметын укыта идем, шул сәбәпле миңа фатирны да Чаллыдан бирделәр. Фатирым 48 нче мәхәлләдәге унберенче йорттан иде. Газизгә дә фатирны шул ук йорттан биргәннәр икән, подъезды гына бүтән. Без аның белән кученгән чакта ук очраштык. Иң элек Газиз миңа эндәште, мине белә булып чыкты. Мин дә аның, хакында яшь язучы буларак хәбәрдар идем.

Танышуыбыз берничә ел элек Казанда булган икән. 1968-1971 елларда мин күренекле галим Хатип Госман җитәкчелегендә аспирантурада укыдым. Ә һәр аспирантның уку планында педпрактика да каралган. һәр аспирант күпмедер сәгать студентларга дәрес бирергә тиеш: ул йә лекция укый, йә семинар дәресләр үткәрә. Мин дә, шул уку программасына кергән сәгатьләр исәбеннән, читтән торып укучы студентларга ике ел рәттән борынгы әдәбият буенча лекцияләр укыдым. Ул студентлар арасында Газиз Кашапов та булган икән, мине шуннан белеп калган. Ә Чаллыга килгәч, без аның белән, инде әйткәнемчә, яңа фатирларга кученгәндә очраштык. Газиз үз фатирына миннән алдарак

килгән булып чыкты. Мин әле әйберләрне ташып кына йөри идем, ул:
«Без инде күченеп беттек, әйберләрне урнаштырып бетерэсе генэ бар. Әйдә, керик! Күрерсең!» - диде. Мин ул көнне, күченү мәшәкатьләре белән, аларга керә алмадым. Урнашып беткәч, без бик еш йөрешә торган булып киттек.

Беренче керүемдә ук фатирында китапларнын, куп булуына игътибар иттем. Китап белән тулы шкафлар хәтта коридорда да тора, ә Газизнең эш булмәсендә бетен өч як дивар буена киштәләргә китаплар шыплап тезелгән иде. Анда татар, рус язучыларыньң әсәрләре генә тугел, ә бөтенденья әдәбиятыннан Теодор Драйзер, Эмиль Золя, Флобер, Мопассан, Голсуорси, Джек Лондон һәм башка классикларнын матур тышлы томнары. Газизнең үз алдына зур максат куеп, җаны-тәне белән иҗатка бирелеп яшәгән чагы иде бу. Шушы 1980 елларда ук инде үз тормышының төп мәгънәсен бары иҗатта гына күрә иде ул.

Шул елларда Газиз «Социалистик Татарстан» газетасыньң Чаллы төбәге буенча узхәбәрчесе булып эшләде. Чаллыдагы бер генә әһәмиятле вакыйга да аньң игътибарыннан читтә калмады; вакыйгаларның үзәгендә булды ул. Чаллы төбәгендәге барлык сәнәгать оешмалары, аларныц житәкчеләре белән танышып, дуслашып яшәде. Тагын шунысы бар: ул басма сүзнең тәэсир-йогынтысың, әһәмиятен, кыйммәтен бик тирән бәяли, үзенең һәр басылган мәкаләсе, әдәби әсәре өчен балаларча шатлана иде. Шундый гадәте бар иде аньң: газетада яки журналда басылып чыккан әсәрен яисә мәкаләсен язу өстәле каршына яки китап шкафының иң күзгә куренеп торган бер урынына беркетеп куя да, шуна сокланып карап утырырга ярата иде. Аньң бу гадәтен белеп алгач, мин аньң чынлап та бөтен барлыгы белән иҗатка бирелеп яшәвенә тагын да ныграк инандым.

Күрше йортта гына шагыйрь Нәҗип абый Мадьяров та яши иде. Без өчәүләп җыелышып, сөйләшеп-гәпләшеп йөри башладык. Бераздан мондый очрашулар гадәткә әйләнеп китте. Шулай итеп Чаллының 48 мәхәлләсендә татар иҗат әһелләренең кечкенә генә бер теркемен, үзебез әйткәнчә, «өчлеген» оештырган кебек булдык. Кышкы кичләрдә, эштән кайткач, өчәүләп йә урамда һава сулап, фикерләшеп йөрибез, яки кайвакыт Газиз безне үз бүлмәсенә чакыра, һәм аларда озак кына сөйләшеп утыра идек. Әдәбият яңалыклары, бигрәк тә Чаллыдагы яңалыклар турында гәпләшә идек. Әйе, Татарстан Язучылар берлегенең Чаллы бүлеге яңа гына оешып килгән чаклар иде ул. Кызганыч, эле кичә генә булган кебек бу хәл-вакыйгалар инде кабатланмас булып үттеләр дә киттеләр, тарихка әйләнделәр. Ул көннәрне буген дә сагынып искә алам, хәтеремдә яңартам. Уйлап карасаң, чыннан да гаҗәп бит: безнең ул вакыттагы «өчлек»тән буген ни Газиз Кашапов, ни Нәҗип абый Мадьяров юк, алар инде куптән гүр иясе булдылар. Беренче булып арабыздан, яшь булуына да карамастан, Газиз Кашапов китеп барды, 2000 елда гажәеп кешелекле өлкән иптәшебез Нәҗип абыйны да соңгы юлга озаттык.

Кырык сигезенче мәхәлләдә бер ел чамасы яшәгәч, миңа фатирны алмаштырырга туры килде, егерменче мәхәлләдәге жиденче йортта яши башладым. Икебез ике өлкәдә эшләп,

бер-беребездән читтэрәк яшәсэк тә, узара аралашуыбыз тукталмады. Мин, désинститутта укытучы буларак, бөтен барлыгым белән вуз тормышына кереп

чумган идем. «Тырышып укы!», «Тырышып эшлә!» дигән тәрбия балачактан ук каныма сеңгән, шуңа курә бөтен тырышлыгымны укытуга багышларга, туплаган белем һәм тәҗрибәмне студентларга бирергә тырыштым. Аудиториядә яшьләр утыра. Э минем, шөкер, алар белән уртаклашасы рухи байлыгым шактый: Казан университетында аспирантурада укыганда да, Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында фәнни хезмәткәр булып эшләгәндә дә, Санкт-Петербург университетында стажировка узганда да шактый гына гыйлем һәм тәҗрибә туплаган идем. Ә менә хәзер борынгы татар әдәбияты буенча җыйган белемнәремне студентлар белән бүлешергә җай чыкты, һәм мин моңа җиң сызганып тотындым. Шуна күрә, Газиз кебек әдәби иҗат белән шөгыльләнәсем килсә дә, минем моңа вакытым да, мөмкинлегем дә калмый иде. Фатирны Чаллыдан алсам да, мина эле һаман Алабуга techинституты укытучысы да булып калырга туры килде, чөнки Алабугада борынгы татар әдәбиятын укытырга белгеч юк иде. Ә Чаллы институтында мин, алда әйткәнемчә, ике факультетта да «Татар балалар әдәбияты» предметын алып бара идем. Дәресләрне шулай бүлергә туры килде: атнанын, дүрт көнендә мин Алабугада, ә калган ике көнендә Чаллыда. (Болай ике шәһәр арасында йөреп укытуым ун елга сузылды.) Шул рәвешле, Газиз белән очрашуларым сирәгәйде. Дөрес, ул вакыты-вакыты белән миңа узе килгәли башлады. Шулай бервакыт Нәҗип абый Мадьяров белән бергә килгәннәр икән, мин өйдә булмаганмын; ул минем ишек ярыгына шундый язу кыстырып киткән иде: «Без килдек, Әнвәр. Ә син юк, сабакы. Газиз». Икенче очрашкач, анын, «сабакы» дигән сүзеннән рәхәтләнеп көлештек.

Сирәк күрешсәк тә, Газизнең «Язмышыңа ышан» дигән роман язуын белә идем. Шулай бервакыт, 1984 елньң кышкы бер көнендә Газизне Алабуга-Чаллы юлы чатында очраттым мин. Дәресләрне бетереп, Алабугадан Чаллыга кайту өчен очраклы машина көтеп тора идем. Э Газиз шул юл чатына Чаллыдан килеп төште. Ул Алабуганьң «Прикамнефть» дигән профилакториена бара икән. Шунда ул миңа «Казан утлары» журналы үзенең эле язылып бетмәгән «Язышьңа ышан» романын бастырырга ризалык бирүе турында әйтте. Менә шул әсәрне язып бетерү өчен ял йортына китеп барышы икән.

Газиз Кашапов Чаллыда башта «Ләйсән» әдәби берләшмәсен, аннан Чаллы Язучылар булеген җитәкләде. Без аньщ белән һәрвакыт бер-беребезне күздән югалтмыйча, бер-беребезнең иңсәсен тоеп яшәдек. Минем - Газиз квартирасына, аның минем фатирга кереп сөйләшеп утырулары дәвам итте. Шул утырышуларда ул мина «Сәмум җиле» әсәренең ничек язылуын, ком чүлендә нинди хәлләрдә калуын да, Уралда Хәсән Туфан эзләреннән йөреп кайтуын да, үз башыннан узган башка вакыйгаларны да җентекләп сөйләгән иде. Һәр чыккан китабын мина автограф белән бүләк итә барды. Менә «Еллар тыныч иде» дигән повесть һәм хикәяләр китабы. Анда: «Әнвәр! Чаллыда яшәгән еллар истәлеге булсын бу китап. Өр-яңа иҗат уңышларына иреш! Газиз Кашапов. Февраль, 1984 ел» дигән кадерле сүзләр бар. «Гомернең утлы өлеше»

китабына: «Әнвәргә! Әдәбиятыбызның зурлыгын, ихтирамга лаек икәнлеген күрсәтүгә гомерен багышлаган дуска - иң изге теләкләр белән. Газиз Кашапов. Январь, 1986 ел» дип язылган. Ә «Вождан хәтере» китабын ул «Әнвәр дус! Милләтебезнең байлыгы өчен көрәшләрдә бер сафта булсак иде. Ихластан, Газиз Кашапов. 7 январь, 1990 ел. Чаллыяр» дип язып бүләк итте.

Газиз турындагы кайбер мәгълуматлар көндәлекләремдә дә теркәлеп калган (вакыт тар булу сәбәпле, алар кыска-кыска гына итеп язылганнар). Менә аларның кайберләре. *«1981 ел, 18 сентябрь. Кич белән сәгать алтыда «Энергетик» мәдәният сараенда «Ләйсән» әдәби берләшмәсенең отчет-сайлау җыелышы булды. Берләшмә җитәкчесе итеп яңадан Газиз Кашаповны сайлап куйдык.» «1981 ел, 12 октябрь. Газиз Кашапов Чаллы Язучылар оешмасының пропаганда бүлегенә эшкә урнашкан.» «1982 ел, 6 март. Кичке сәгать алтыда Алабуга пединститутының Чаллы филиалында студентларның язучылар белән очрашуы булды. Аны оештыручы мин идем. Очрашуны Разил Вәлиев алып барды. Язучылардан Эдуард Касыймов, Газиз Кашапов, Нәҗип Мадьяров, Хәниф Хоснуллин, Рәшит Бәшәровлар килгән иде.» «1982 ел, 9 апрель. «Энергетик» мәдәният сараенда җыр кичәсе булды. Залда без Газиз һәм аның хатыны Фәһимә белән бергә утырдык. Шыгрым тулы залда җырчы Габидулла Хөрмәтуллин Газиз Кашаповның «Әтием, бәгърем» җырын башкарды. Шул чакта Газиз: «әниләр турында җырны күп язалар. Ә менә әтиләргә багышланганнары юк. Бала тәрбияләүдә әтиләрнең дә роле зур бит. Хәзерге заманда әтисез генә баланы тәрбияләп кара! әниләр баланы иркәләргә генә торалар, ә әтиләр аларны билгеле бер рамкаларда тота. Менә шуңарга мин әтиләр турында җыр яздым», - дип горуланып сөйләде.» «1982 ел, 19 апрель. Алабуга пединститутының Чаллы филиалында Казаннан килгән язучылар белән очрашу үткәрдем. Очрашуда Казаннан Рөстәм Мингалимов, Нәбирә Гыйматдинова, Ркаил Зәйдуллин, Ләис Зөлкарнәевләр, Чаллыдан Газиз Кашапов булды.» «1982 ел, 25 апрель. «Энергетик» сараенда Тукай туган көнгә багышлап поэзия кичәсе булды. Әлмэттән Әдип Маликов, Әхәт Гаффар, Энҗе Мөэминова, Клара Булатова, Роберт Рәкыйпов, Илдар Хөснетдиновлар чыгыш ясады. Чаллыдан Разил Вәлиев, Газиз Кашапов, Ямаш Игәнәй, Кадыйр Сибгатуллин, Нәҗип Мадьяровлар шигырь укыдылар.» «1982 ел, 19 декабрь. Миндо Газиз Кашапов, Нәҗип Мадьяровлар булды. Сөйләшеп утырдык.» «1983 ел, 19 январь. «КамАЗ» клубында М. Мәһдиевнец «Борчулы өчө» исемле моңсу комедиясен Газиз Кашапов белән бергә карадык.» «1983 ел, 30 январь, якшәмбе. Иртән иртүк Газиз Кашапов белән Нәҗип Мадьяров килеп керделәр. Сәгать уникегә кадәр сөйләшеп утырдык.» «1983 ел, 1 апрель. Студентларның тулай торагында Газиз Кашапов, Нәҗип Мадьяров, Кадыйр Сибгатуллиннар белән очрашу үткәрдем. Профессор Г. Х. Әхәтов та катнашты.» «1983 ел, 5 апрель. Газиз Кашаповның «Җир җылысы» повестена рецензия яздым.» «1983 ел, 24 май. Кичен Газиз янына барып килдем. 22 майда «Социалистик Татарстан»да минем Газиз Кашапов повесте турындагы*

*рецензиям басылган.» «1984 ел, 25 апрель. Пединститутның Чаллы филиалында шагыйрьләр белән очрашу үткәрдем. Казаннан Рәишт Әхмәтҗанов, Әхмәт Рәшитов, Чаллыдан Газиз Кашапов, Нәҗип Мадъяров, Ямаш Игәнәйләр катнашты. Кичәне ректор Зиннур Тәлгатович Шәрәфетдинов ачты, мин алып бардым. Аннан соң Газизләрдә сөйләшеп утырдык: Газиз, Зиннур Тәлгатович, Нәҗип абый, Ямаш Игәнәй һәм мин. Шунысы хәтердә калган: бу кичәдә Газиз Кашаповның бер студент кызның лейтенант белән үбешүе турындагы шигыре аеруча көчле алкышларга кумелгән иде.» «1984 ел, 30 декабрь. Буген миңа Газиз Каилапов килде. Аның белән күптән сөйләэшеп утырган юк иде, сөйләшеп утырдык, китаплар карадык.» «1985 ел, 25 январь. Брежнев Язучылар оешмасы утырышында Газиз Кашапов иҗаты турында доклад сөйләдем. Буген аның иҗат отчеты булды.»*

Көндэлектэге шушындый язуларны кайвакыт укып утырам да Газиз дустым белән аралашып яшәгән елларны сагынып куям. Газиз чын мәгънәсендә янып яшәде. Якын танышларын, дусларын да үзенең үрнәгендә яшәргә өйрәтте. Аның белән аралашудан мин үземә күп яхшы нәрсәләр алдым: максатларымнан читкә тайпылмыйча барырга тырышып яши башладым. Мин аңа бик рәхмәтлемен!

Булган кеше барын да булдыра бит ул. Газизгә мин тагын шуның өчен дә рәхмәтле: ул, 1986 елда XVIII-XIX гасырларның күренекле шагыйре Габдерәхнм Утыз Имәнинең (әдәбият тарихында беренче тапкыр!) «Шигырьләр, поэмалар» дигән китабын бастырып чыгаруымны искә алып, мине «КАМАЗ төзелеше ударнигы» дигән мактаулы исем алачак язучылар исемлегенә керткән иде, һәм миңа 1989 елның декабрендә шуның таныклыгын тапшырдылар. Ә ул таныклыкка ия булган кешеләргә Чаллы шәһәр транспортында (автобус, трамвайларда) бушлай йөрү хокукы бирелә иде. Шулай итеп, мин, үзем һич көмәгәндә, шәһәр транспортында бушлай йөрү хокукына ия булдым. Шуннан алып, ошбу карар узгәртеп кору елларында гамәлдән чыгарылганга кадәр, мин автобус һәм трамвайларда йөргән чакта һәрвакыт Газизне искә төшереп, аңа рәхмәтләр укый идем.

Әле күптән түгел генә, быел август аенда, без, бер төркем Чаллы язучылары, Газиз Кашаповның тууына 80 ел тулу уңае белән, аның туган җирендә - Аксубай районының Яңа Учи авылында очрашуда булып кайттык. Авылдашлары Газизне бик хөрмәт итәләр икән: мәктәп каршына бюсты куелган, ә мәктәптә аның бик эчтәлекле музеен оештырганнар. Әлеге кичәдә Факил Сафиннан соң чыгыш ясап, Газиз иҗатына нисбәтле материалларымны аның музеена тапшырдым; аннан соң зиратка барып, аның каберенэ чәчәкләр куйдык. Дустым рухына багышлап догалар укыдым.

Газиз минем күңелемдә һәрчак тере-исән якты образ булып яшәп килә. Ә китап укучылар аны дулкынландыргыч - елата да, сөендерә дә, уйландыра да торган әдәби әсәрләре аша искә алалар. Үзеңнең вафатыңнан соң да кешеләр тарафыннан хөрмәт ителү - ул һәркем хыяллана торган биеклек һәм бөеклек бит!

Әнвәр ШӘРИПОВ,<br>филология фәннәре докторы,<br>профессор.